# Тирсә авылы тарихы эзләреннән

2017



Тирсә бай тарихы, тырыш, иҗади күңелле кешеләре белән горурлана. Авылыбызда туып үскән белем ияләре бөтен җир шары буенча таралган. Кемнәр генә юк алар арасында: журналист, дипломат, язучы, шагыйрьләр... Алар кайда гына яшәсәләр дә, татар телен, татар мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә зур көч куялар. Безнең тарихи тамырларыбыз өзелмәгән, алар ныгый гына баралар, чөнки хәзерге авылдашларыбыз арасында да каләм тибрәтүчеләр шактый. Аларның һәр уңышына ихластан сөенеп яшибез.

Адресыбыз: Әгерҗе районы,
Тирсә авылы, Көнчыгыш ур., 19
Электрон почта: tersi@inbox.ru

# Тарихи сәхифәләр

- 14 -15 гасырларда борынгы бабаларыбыз, Оренбург өлкәсеннән Шәде елгасы буена килеп нигез сала, авылга Тирсә исеме бирелә. Бу исемне бирүнең сере шунда: алар Оренбург өлкәсендәге Тирсә елгасы буендагы Тирсә авылында яшәгән булалар.
- Россиядә Екатерина II патшалык иткән чорда Урта Азияне яулап алуда күрсәткән сугышчан хезмәте өчен Мөхәммәт Морза ТәфкилевкаТирсә волостена кергән авыллар бүләк ителә.
- 1742 нче елда, хөкүмәт һәм алпавыт тарафыннан изүләргә түзә алмыйча, крестьяннар баш күтәрәләр. Сугыш башлана.





- 1742-1744 нче еллардагы восстание җиңелү белән тәмамлана.
- 1773 -1775 нче елларда Пугачев җитәкләгән крестьяннар хәрәкәтенә тирсәлеләр дә кушыла. Крестьяннарны Әбҗәлил Сөләйманов җитәкли.
- 1803 нче елда Тәфкилев шырпы, пыяла, кирпеч - пыяла заводлары төзетә, мунчаладан кап сугу, сумала әзерләү, тире эшкәртеп күн ясау һөнәрчелек остаханәләре калайдан көнкүреш кирәк-яраклары ясау оештырыла.
- 1893 нче елдан рәсми теркәлгән. Аучылар җәмгыяте булган.
- 1918 нче елга кадәр Тирсә авылы волость булып торган.



- 1918нче елда Тирсә волосте аклар кулында кала, 1919 нчы елның августында Азин тарафыннан чистартыла.
- 1923нче елда авылда беренче комсомол оешмасы төзелә.
- 1924нче елда клуб һәм китапханә ачыла.
- 1929 нчы елда Тирсәдә “Кызыл Тирсә” колхозы төзелә.
- 1935нче елдан Киров исемендәге колхоз дип йөртелә башлый.
- Тирсәдән 390 кеше фронка китә, 205 кеше хәбәрсез югала. 95 кире әйләнеп кайта.
- 1941нче елда Тирсә МТСы каршында кыска сроклы тракторчылар хәзерләү курслары ачыла.
- 1980 нче елда Тирсә тимер юл станциясе төзелеп бетеп, поездлар йөри башлый.



1700 нче елларда авылда мәчет төзелә, проекты Юськи авылы чиркәү проекты белән алмашына. Мәчет чиркәүгә охшаш була. Манараның озынлыгы 41 метр. Тирсә мәчете крепостной крестьяннар көче белән кирпечтән салына. Бөек Ватан сугышыннан соң мәчет сөт – май комбинаты итеп үзгәртелә. 1983нче елларда комбинат эштән туктый.Тирсәнең мәһабәт тарихи мәчете бинасы 1991 нче елда җимертелә.



1999 елда авылда яңа мәчет ачыла.



Тирсә үзәк урамының кибете янында тимер чардуганлы кабер бар. Анда колхозлашу елларында кулаклар тарафыннан кыйнап үтерелгән Бакиев Баһаветдин күмелгән.






Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырлар хөрмәтенә куелган һәйкәл. Бөек җиңүнең 65 еллык уңаеннан яңа обелиск ачыла.





Тирсә авылында 1815 нче елда мәдрәсә ачылган. 1882 нче елда земство тарафыннан башлангыч мәктәп ачылган.



Кыз балалар укыган абыстай йорты



1919 нчы елда Тирсә авылында дүртьеллык мәктәп ачыла. Беренче директоры –Гыйният Адылов.



1924 нче елда Тирсәдә пионерлар отряды төзелә. Аңа “ Париж коммунасы“ исеме бирелә.



1926 нчы елда Тирсә мәктәбе җидееллык итеп үзгәртелә.



1939-1940 нчы уку елында ул сигезьеллыкка әйләнә.



1970 нче елда яңа мәктәп бинасы салына. 1988нче елда Тирсә мәктәбе урта мәктәп итеп үзгәртелә.



2007 нче елның 30 нчы ноябрендә яңа мәктәп бинасы ачыла.

# Шигърият



## *Заһирә Байчурина*

***(1890 – 1977)***

Тирсә авылында мулла гаиләсендә туа. Әнисе Тирсәдә кырык ел буе балалар укыта. Иж-Бубыйдагы кыз балалар мәдрәсәсен тәмамлый һәм туган авылына кайтып мөгаллимә була. Уфада, Пермь шәһәрендә кызлар мәктәбендә эшли. Октябрь революциясеннән соң З.Байчурина, Пермьнән торып, Мәскәүдәге һәм Казандагы татарча газета-журналларга актив язышa. 1923нче елда З. Байчуринаның «Шигырьләр мәҗмугасе» басылып чыга. Шул ук елда бер төркем шигыре «Көрәш җырлары» исемле күмәк җыентыкка да урнаштырыла. З. Байчуринаның сайланма шигырьләре 1959нчы елда чыккан «Ана сүзе» исемле китабына тупланган. Заһирә Байчурина 1977нче елның 26 декабрендә Махачкала шәһәрендә вафат була.


**“Шагыйрьләр туа торырлар...”**

**К.Сибгатуллин**

### *Үпкә*

Үстердең лә, әнкәй, мин кызыңны
Күрсәтмичә җилгә, буранга;
Яман күздән саклап, бер ялгызым
Чыгармыйча хәтта урамга.
Көнләшерлек иде гөл чәчәге
Ак йөзләрем, зифа буйларым;
Нурлы балкый иде киләчәгем,
Татлы иде яшьлек уйларым.
Юкка чыкты хәзер бар уйларым.
Вәйран булды зифа буйларым;
Хыялларым өндә күрә алмадым,
Янып көлгә очты шул бары:
Ундүрт яшьтә иргә ярәштең дә
Мине саттың шомлы сәгатьтә.
Булыр иде артык мең мәртәбә,
Үрнәк алып вәхши гарәптән,
Тереләй күмсәң мине тар кабергә,
Тиз үк чыгар иде пакь җаным.
Яр кылдыгыз күңлем сөймәгәнгә, -
Гомрем буе сүнмәс аh-зарым!





## “Күңелләр тула торырлар, Бу җаннар тынмас инде.”

К.Сибгатуллин

### Фазыл (Фердинант) Шәех


*(1937 -2001)*



Иске Кызылъяр авылында туып үсә. 1951 нче елда Тирсә мәктәбен тәмамлый. Казан авыл хуҗалыгы институтында инженер-механик белгечлеге ала. 1967нче елда, Әгерже районы авыл хуҗалыгы идарәсендә баш инженер булып эшләгәндә, Фердинантның күзләре сукырая. Типсә-тимер өзәрдәй якташыбыз зар елап, ачы язмышына буйсынып, сыгылып төшми, кимсенеп яшәми, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Татарстан язучылар союзы әгъзасы. Аның “Якты юл буйлап”, “Көзге күкрәү”, “Дала тулпары” җыентыклары нәшер ителә, шигырьләре Республика матбугат битләрендә еш басылып чыга. Фазыл Шәех безнең күңелләрдә кешеләргә, туган ягына мәдхия җырлаучы олы йөрәкле илаһи зат булып калыр.

### *Туган җир яме*

Сабый чагым болыннары,
Уйнап чапкан колыннары
Күңелемә якын иделәр.
Мине сабан тургайлары,
Җир җиләкле тугайлары
Туган җиргә гашыйк иттеләр.
Болыннарда атлар көттем,
Яшь гөлләрне сөеп үптем.
Алар нурлы, назлы иделәр.
Чаж суының дулкыннары,
Туган якның киң кырлары
Мине моңга, җырга илттеләр.
Әткәм белән әнкәм юлга,
Кояш бүләк итә иделәр.
Сагынып кайтып кергәндә,
Исәнлегемне күргәндә,
Тулган айга пар, тиң иделәр.
Киләчәккә юл ярганда,
Сөю утларым янганда,
Язлар мине шагыйрь иттеләр.






## Гөрләп, дөрләп, яна-яна яшим



***Чыңгыз Мулламөхәммәт улы Мусин***

1934 нче елда Тирсә авылында туа. 1997нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Соңгы елларда “Әгерже хәбәрләре” район, Ижау каласында нәшер ителә торган “Яңарыш” газеталарының Әгерже районы буенча махсус хәбәрчесе. Шагыйрь районыбыз тарихын өйрәнү буенча зур эш башкара. Шуның матур нәтиҗәсе булып “Әгерже төбәге тарихы” исемле монографик хезмәте нәшер ителде. Чыңгыз Мусин – алты шигырь җыентыгы авторы. “Язмышым үзәннәрдә”, “Тамырлар”, ”Кадер кичендә”, “Гомер юлы”, “Карт каеннар шау чәчәктә” һәм “Баганалы юллар” район һәм Казан матбугатларында дөнья күрә. Күп кенә шигырьләренә көйләр язылган. Аның шигырьләрендә үзе күргән-татыган, башыннан кичергән тормыш чынбарлыгы, туган як кешеләренең күңел күзе аша уздырып гәүдәләндергән самими образлары, уй – хисләре, өмет–хыяллары, халкына булган чиксез мәхәббәте чагыла.

## Гаҗәп гүзәл иҗат юлында

***Тукай рухы, заман агышы***

Мин шигырьдә Тукай булалмадым,
Яшем җитте алты дистәгә.
Тик шулай да еллар узган саен
Тукай рухы миңа өстәлә.

Хыялыма гүя чабам кебек,
Тукай иярләгән атларда.
Күпләр бүген олы бәя бирә,
Аның кебек асыл затларга.

Миннән олуг шагыйрь чыкмаса да,
Мин барыбер шул ук “көймәдән”.
Ярый әле шушы серле дөнья,
Күңелемне минем биләгән.



**Иҗатым юлларымны минем нурлады.**



*Динар Хаҗи улы Абдуллин*


*(1950 -2000)*

Тирсә авылында туган. Өч яше тулгач, әнисенең туган авылы Биектауга күченәләр. Беренче шигырьләре дә мәктәпнең әдәбият түгәрәге җитәкчесе, Розалия апа Солтанова ярдәме белән туа. 1971 нче елда Ижау каласына күчеп килә, шул еллардан башлап "Яңарыш" газетасының иң популяр авторы була. Шигырьләрендә авыл тормышы, аның табигате, мәхәббәт, сөю төшенчәләре түргә менеп утыра. Шагыйрьнең "Иртәнге чык тамчылары", "Мирас" шигырь җыентыклары дөнья күрә, әсәрләренең күбесе сәламәтлеге какшаган, каты авыру белән көрәшү чорында язылган. "Соңлама", "Туган якның изге туфрагы", "Зур бәйрәмең белән, әнкәм", "Сау бул, мәктәп ", "Мәңге яшә, әнием!" шигырьләренә көйләр язылган.

**Бирде дөнья кирәкне,**
**Еламаска өйрәтте.**
**Х.Туфан**

***Яшьлегем бишеге***

Һәркемнең дә үз яшьлеге матур,
Уздырсак та аны төрлечә...
Ни әйтсәң дә, авыл баласының
Яшьлек хатирәсе көчлерәк.
Табигатьнең кочагында үскәч,
Тәэсире дә матур төслерәк.
Иртән эчеп яңа сауган сөтне,
Ялан тәпи кырга чыгып чап.
Урманда йөр, тыңла кошлар моңын,
Ике килми безгә балачак.
Синең якын танышларың була
Һәр җәнлеге, корты, бөҗәге.
Алар да бит табигатьнең безгә
Бүләк итеп биргән бизәге.
Әкрен генә сине тартып ала,
Җибәрми бит авыл хезмәте.



# Югалтырга мөмкин түгел икән



***Әнисә Касыйм кызы Кәримова (Галиева) (1937-2002)***

Мәктәптә татар теле һәм әдәбият, немец телләрен укыткан. Шигырьләре районда нәшер ителгән, “Үз моңым бар җирдә”, “Күңел чишмәләре”, “Яшьлегем сиреньнәре” дип исемләнгән җыентыкларга кертелгән. Керсез дуслыкка, саф мәхәббәткә, табигать матурлыгына, чәчәкләргә сокланып яшәгән, тормыш-яшәеш мәгънәсенә төшенергә тырышкан шигырьләр язган.

# Мәңгелеккә диеп туганны !

***Тукаебыз, кичер безне…***

Яшәгән син халкым кебек:
“Ярлыкагыл, диеп,- Ходам!”
Инкыйлабтан соң (кызганыч!)
Изге сүзләр онытылган.

Туры Тукай! Сине уйлап
Бүген йөзләр һай кызара...
Тулы иҗатын өйрәнми
Гомерләр узганга.

Шөкер, соңрак булса да,
Кыйблабызга кайтып килеш.
Яшь буынга шифа булсын
Мирасыңнан “тапкан” өлеш.



# Проза



***Хәмит Рәхимов***
***(1899-1939)***

Тоба авылында 1899 нчы елны ярлы крестьян гаиләсендә туа. Тирсә һәм Иж-Бубый мәдрәсәләрендә укый. 1929 нчы елдан ВКП(б) члены. 1922-1931нче елларда Ижевск заводларында эшли. 1931-1934нче елларда Мәскәүдә Сталин исемендәге милли партия хезмәткәрләренең үзәк курсында укый. Әгерҗедә партия кабинеты мөдире.1935нче елда каты авырып, ике аяксыз кала. Ләкин авыр тормыш сынаулары да аның әдәбиятка булган мәхәббәтен сүндерә алмый. 1936нчы елдан СССР Язучылар Союзы члены. М.Җәлил, А.Алишлар белән иҗади багланышта тора. Хәмит Рәхимовның түбәндәге китаплары билгеле: “Чишмә буенда” повесте, “Киселгән орлыклар” хикәясе, “Тоткын Сәрвиназ” пьесасы. 1940нчы елда “Совет әдәбияты” журналында Х.Рәхимовның “Сөремле кисәү”, “Алмаз” исемле пьесалары басыла. Бу әсәрләрне Татар дәүләт академия театры үз репертуарына ала, ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, сәхнәдә куелмый кала.

## Иҗат – гүзәл гамь ул

***Чишмә буенда***
***(повестьтан өзек)***

(Әсәрдә авылда яшәгән батракларның байлар тарафыннан изелүләрен тулы итеп чагылдыра). “Авыр көннәр бер-бер артлы озакка сузылдылар.Тажи байга ашлык суккан чагында, авыл ярлылары арасында бер яңа мәсьәлә куәтләнде. Алар хат аркылы, Сабит шахтёрдан эшне белешмәкче була. Сүзне, тәмәке тартканда, чандыр гәүдәле, озын буйлы, ак төшеп бер күзе пыялаланган Фазлый башлап китте:
- Хат язганда, барырга теләүчеләрне әйтеп язарга кирәк; барып җитәр өчен күпме акча кирәк булуын да сорарга кирәк. Мин, егетләр, артык кәҗәне сатып булса да китәм. Бу тормыштан качам. Авыл байларына никадәр эшләсәң дә, тамагың да туймас. Өстең дә бөтәймәс, дип ертык бишмәтенең итәген тотып селекте.

# Вакытлы матбугат



***Зарипова (Нуриева) Рәмзия Сабир кызы***

Тирсә авылында туып үсә. 1982нче елны Казан Дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Гомер юлын, иҗат дөньясын туган ягына багышлый. Корреспондент, 2000нче елдан “Әгерҗе хәбәрләре” гәзитенең баш мөхәррире. Киң эрудицияле, үткен телле оста каләм иясе, тыйнак, кешелекле шәхес иҗат коллективын туплап, Әгерҗе данын үстерүгә зур хезмәт куя.




***Абзалиева Дания Зәңгир кызы***

1969 нчы елны Биектау авылында туып үсә. Башлангыч сыйныфларда укыганда ук беренче укытучысы Салисә апа Халитова иҗади эшкә дәртләндерә, ә әдәбият укытучысы Гыймазова Вәсилә апа ярдәмендә мәкаләләре район гәзите битләрендә урын ала.

1999нчы елдан Иҗауда нәшер ителүче “Яңарыш” һәм районгдагы “Әгерҗе хәбәрләре” гәзитләре корреспонденты. “Минем Удмуртия” телеканалында балалар өчен “Күңелле кыңгырау” тапшыруын әзерли. Зирәк, шома телле корреспондент; туган ягындагы матур эшләр, шушы эшләрне башкаручы замандашлары турында язмалар әзерләү аңа иҗади дәрт өсти.

# Дөнья дигән бөек китапка
# Языла бара хезмәт юлларым




***Йолдыз Нури улы Хәлиуллин (1936 )***

Иске Кызылъяр авылында туып үсә, 1951нче елда Тирсә мәктәбен тәмамлый. Мәскәү Дәүләт Халыкара мөнәсәбәтләр институтында (МГИМО) укый. Профессиональ дипломат, күп еллар Якын Көнчыгыш илләрендә илче эшчәнлеген башкара. Дистәгә якын Көнбатыш һәм Якын Көнчыгыш илләренең телләрен камил белә. Галим, язучы һәм публицист, Евразия Халыкара икътисад академиясе мөхбир әгъзасы. Соңгы елларда, мөселман илләрендәге Нобель премиясе лауреатлары һәм мәшһүр татар галимнәренең хезмәтләрен туплап, монографик хезмәтләр, мәкаләләр язып чыгара, чит илләрдә лекцияләр укый. Мәскәүдә яши.












# Тормыш үзе биргән сәләтне



***Ногманов Нәзир Нәзил улы***


2010нчы елда Удмурт дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлап, Удмуртия Республикасының “Яңарыш” мәгълүмати-нәшрият үзәге мөхәррире. Башлангыч сыйныфларда укыганда ук матур әдәбият уку белән мавыга. “Яңарыш “, “Әгерҗе хәбәрләре” газеталары битләрендә ”Тылсымчы булсам”, ”Китап сөючеләр бәйгесе”, ”Тормышка ямь бирүче”, ”Юбилеең белән, ветеран”, ”Сугылырга онытма” кебек мәкаләләре һәм “Төшемә керәсең, эти” исемле шигыре басылган булса, студент елларында бүгенге көн өчен актуаль булган мәсьәләләрне яктырткан “Хезмәт төбе—хөрмәт”, “Тормыш йомгагын сүткәндә”, “Таркалган хәтер”, ”Эчә дә, яши дә белмибез түгелме?” кебек мәкаләләре белән сөндерә.

# Композиторларыбыз



*Әнвәр Закиров*

Әнвәр Закиров1930 нчы елда Бондюг районының Песәй авылында туа.
Алабуга педагогия институтының рус теле бүлеген тәмамлый.
Хезмәт юллары – укытучы, мәктәп директоры, райком инструкторы һәм бүлек мөдире. Соңгы елларда район газетасы редакциясендә эшләп пенсиягә чыккач, Тирсә авылында яши.
Ул искиткеч шигъри һәм музыкаль сәләткә ия булган кеше. Күп санлы музыка әсәрләре иҗат итеп калдырды. “Син минем йолдызым” дигән җырлар авторы.



## Моң керде күңелгә



*Фәния Фәхретдин кызы Мөхәммәтшина*

Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты, музыка укытучысы булып эшләде. Буш вакытларында шигырьләр, җырлар яза. Н.Нәбиуллин, Ч.Мусин, Г.Әхтәмова, Р.Байтимерова сүзләренә язылган җырлары бар.

# Рәссамчы



*Һәдия Ситдикова*


Башкортстанның халык рәссамы, Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты. Әгерҗе районы, Мордывый авылында туа. Хәзерге көндә Уфада яши.




Зәңгәр шәл



Икмәк



Туй алдыннан



Татар балы



Башкорт балы

# Актив хәбәрчеләр



***Роза Мифтах кызы Корбанская***

1950 нче елда Мордывый авылында укытучылар гаиләсендә туа. Мәктәптә укыганда татар теле һәм әдәбият укытучысы Гыймазова Вәсилә Миннегәрәй кызы оештырган түгәрәккә йөри, шуннан башлап иҗат эшенә кызыксыну уяна. Соңыннан мәктәптә башлангыч сыйныф укытучысы, “Сельхозтехника”, “Сельхозхимия” берләшмәләрендә эшли. Хикәяләре, публицистик язмалары, шигырьләре ”Әгерже хәбәрләре”, “Татарстан яшьләре” гәҗите битләрендә басыла. Районыбыз гәзитенең актив хәбәрчесе.

## Талантлы син, Кеше туганым



***Фирая Зөфәр кызы Әхмәтҗанова***

Язмыш җиле Фирая апа Әхмәтҗанованы Тирсә якларына алып килә.Туган якның илһамлы җиле кулына каләм алырга этәрә. Аның шигырьләре, мәкаләләре даими рәвештә “Әгерже хәбәрләре”, “Яңарыш” гәзите битләрендә басылып тора.

## Мәктәбебез очырган кошлар



***Рәмзия Шәймухаметова***
Әгерҗе хәбәрләре, Яңарыш газеталарының актив хәбәрчесе. 1962 елларда Тирсә урта мәктәбен тәмамлаган. Белгечлеге буенча шәфкать туташы.




***Роза Никашева***
Гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган мөгаллимә, “Әгерҗе хәбәрләре”, “Яңарыш” газеталарының актив хәбәрчесе.

## Сәләтле без һәрбер иҗатка!

***Нурания Көбәш***








Ленин юлы. 1960 ел. ...рында

УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

Тирсә җидееллык мәктәбендә әдәбият түгәрәге эшли. Түгәрәккә укучылар зур кызыксыну белән йөриләр. Алар анда мәкаләләр, шигырьләр язарга өйрәнәләр.

Түбәндә без түгәрәк члены, VI класс укучысы Нурания Мифтахованың ике шигырен урнаштырабыз.

**ТАҢ АТТЫ**

*Матур булып таң атты,*
*Кошлар канатын какты;*
*Зәңгәр урман җанланды,*
*Тау битләре алланды.*
*Офыктан кояш чыкты,*
*Нурга манды җир өстен;*
*Әкрен искән таң җиле,*
*Шадралатты күл өстен.*

**Язгы табигать**

*Яз җитүгә шәһәр, авыллар,*
*Бакча эчләрендә калалар;*
*Алмагачлар, нәфис сиреньнар,*
*Матурланып чәчәк аталар.*
*Сокландыргыч матур көннәрең!*
*Гөрләвекләр шаулап агалар.*
*Урманнарда хуш ис таратып,*
*Ак каеннар яфрак яралар.*
*Уҗым баш калкыта басуда,*
*Яшел келәм каплый кырларны.*
*Зәңгәр күккә күтәрелеп,*
*Тургай сайрый язгы җырларны.*

**Үткән тарихыбыз, дуслар,**

**Күңелдә озак калсын.**

**Якты мирасыбыз булып,**

**Безне озата барсын.**

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!

**Эшне башкарды: Татарстан Республикасы,Әгерҗе районы, Тирсә авылы.**